ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына аерым категориядәге вазыйфаи затларның коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $6^3$ статьяның 1 өлешендә «кушымтада» сүзен «1 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

2) 29 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасында һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $3^5$ өлешенең 2 пунктында каралган очракларда, муниципаль вазыйфа били торган һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара торган зат, әлеге Законга 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп, коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга хокуклы.»;

3) кушымтаны 1 нче кушымта дип санарга;

4) түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Президенты
______________________________

Коммерциягә карамаган оешма белән
идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу турында
хәбәрнамә

Мин, ____________________________________________________
(муниципаль вазыйфа били торган зат вазыйфасының тулы аталышы)

____________________________________________________________
___________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме)

________ елның «___» ______________ туган, паспорт сериясе ____ № ______________, __________________________________
(паспорт бирелгән дата һәм биргән орган)

_______________________________________________________ бирелгән,

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасы (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата), «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $3^5$ өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Сезгә 20___ елның «__»________ ________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме, урнашкан урыны һәм адресы, эшчәнлек төре,

____________________________________________________________
коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) нинди сыйфатта планлаштырыла)

____________________________________________________________
____________________________________________________________

коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга җыенуым хакында хәбәр итәм.

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) били торган муниципаль вазыйфа буенча вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә яисә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китерми.

20__ елның «____»____________ __________________________
(хәбәрнамә тапшырган затның имзасы)».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) «Татарстан Республикасы» сүзләрен «1. Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $3^4$ өлешенең 2 пунктында каралган очракларда, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын били торган затлар (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш), әлеге Законга кушымтада бирелгән рәвештә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп, коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга хокуклы.»;

2) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
дәүләт вазыйфалары турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Татарстан Республикасы Президенты
______________________________

Коммерциягә карамаган оешма белән
идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу турында
хәбәрнамә

Мин,

______________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы били торган зат вазыйфасының тулы аталышы)
______________________________________________________________

______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме)
_______ елның «___»_______________туган, паспорт сериясе____№_______________, ____________________________________
(паспорт бирелгән дата һәм биргән орган)
______________________________________________________________,
«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $3^4$ өлешенең 2 пункты һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Сезгә 20____ елның «__»________ ____________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме,
______________________________________________________________
урнашкан урыны һәм адресы, эшчәнлек төре, коммерциягә карамаган оешма белән
______________________________________________________________
идарә итү (идарә итүдә катнашу) нинди сыйфатта планлаштырыла)
______________________________________________________________
коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга җыенуым хакында хәбәр итәм.

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) били торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә яисә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китерми.

20____ елның «____»__________ ______________________________
(хәбәрнамә тапшырган затның имзасы)».

**3 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) коммерциягә карамаган яисә коммерциячел оешма белән идарә итүдә катнашырга, моңа түбәндәге очраклар керми:

а) түләүсез нигездә сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) яллаучы вәкиленең әлеге Кодексның $16^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш);

в) «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ статья өстәргә:

«16[1] статья. **Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы**

1. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы яллаучы вәкиленең әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре (алга таба бу статьяда – коммерциягә карамаган оешма) съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш).

2. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яисә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итү турындагы гаризасы (алга таба әлеге статьяда – гариза) муниципаль хезмәткәрнең яллаучысы вәкиле исеменә әлеге Кодекска $2^1$ нче кушымтада бирелгән рәвештә язмача төзелә.

4. Гариза муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе аппараты кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше өчен җаваплы вазыйфаи затка) коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә планлаштырылган катнашу башланганчы тапшырыла.

5. Гариза кергән көнендә кадрлар хезмәте тарафыннан гаризаларны теркәү журналында теркәлә, бу журнал әлеге Кодекска $2^2$ нче кушымтада бирелгән рәвештә алып барыла. Гаризаларны теркәү журналы битләре номер сугылган, шнур белән тегелгән һәм кадрлар хезмәте яисә муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

6. Гаризаның теркәү турында тамга куелган күчермәсе, гаризаны теркәү датасын, номерын, әлеге гаризаны теркәгән кадрлар хезмәте затының фамилиясен, инициалларын һәм вазыйфасын күрсәтеп, муниципаль хезмәткәргә, гаризаларны теркәү журналына аның имзасы куелып, тапшырыла.

7. Кадрлар хезмәте гаризаны алдан карый һәм муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы мөмкин булу йә мөмкин булмау турында дәлилләнгән бәяләмә (алга таба – дәлилләнгән бәяләмә) әзерли. Дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә кадрлар хезмәте гариза биргән муниципаль хезмәткәр белән, аның ризалыгын алып, әңгәмә үткәрергә һәм аңардан язмача аңлатмалар алырга мөмкин.

8. Дәлилләнгән бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яисә башка мәсьәләләр буенча карарлар, шул исәптән шушы коммерциягә карамаган оешма тарафыннан эшчәнлекнең билгеле бер төрен һәм (яисә) аерым гамәлләрне башкаруга рөхсәтләр бирүгә бәйле карарлар кабул итү вәкаләтләренә анализ;

2) муниципаль хезмәткәрдә, ул коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә анализ.

9. Гариза һәм дәлилләнгән бәяләмә гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә яллаучы вәкиленә җибәрелә.

10. Яллаучы вәкиле гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен чыгара:

1) муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт бирергә;

2) муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт бирмәскә;

3) гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне муниципаль хезмәткәрдә, ул коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге булуны яисә булмауны карау өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиягә җибәрергә.

11. Муниципаль хезмәткәрдә, ул коммерциягә карамаган оешма белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге әлеге статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында каралган карарны кабул итү өчен нигез булып тора.

12. Әлеге статьяның 10 өлешендәге 3 пунктында каралган очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне яллаучы вәкиле аларны шушы комиссиягә җибәргән көннән алып җиде көн эчендә карый. Гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия муниципаль хезмәткәрдә, ул коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге булу йә булмау турында карар кабул итә.

13. Әлеге статьяның 12 өлешендә каралган карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә яллаучы вәкиле муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт бирү йә рөхсәт бирмәү турында карар кабул итә.

14. Яллаучы вәкиле тарафыннан әлеге статьяның 10 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында йә 13 өлешендә каралган карарларның берсе кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә кадрлар хезмәте муниципаль хезмәткәргә, гаризаларны теркәү журналында аның имзасын куйдырып, яллаучы вәкиле кабул иткән карар турында язмача хәбәр итә яки муниципаль хезмәткәргә почта элемтәсе аша, тапшыру хакында хәбәр итеп һәм гаризаларны теркәү журналында бу хакта билге куеп, яллаучы вәкиле кабул иткән карар турында мәгълүмат җибәрә.

15. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карауга бәйле башка материаллар (алар булган очракта) муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына кертелә.»;

3) 32 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Дисциплинар җәза бирүләрне куллану һәм кире алу тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнарында билгеләнә.»;

4) 33 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9. Әлеге Кодексның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җәза бирүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булган чорларын, аның чираттагы ялда булуын санамыйча, муниципаль хезмәткәрнең коррупциячел хокук бозу кылуы турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм аның коррупциячел хокук бозу кылган көненнән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча башкару вакыты керми.»;

5) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ нче кушымта өстәргә:

«Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
$2^1$ нче кушымта

______________________________
(муниципаль хезмәткәрне яллаучы
______________________________
вәкиленең вазыйфасы,
______________________________
инициаллары, фамилиясе)

______________________________
(муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы,
______________________________
инициаллары, фамилиясе)
______________________________

Коммерциягә карамаган оешма белән
идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итү турында
ГАРИЗА

Сездән «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «б» пунктчасы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының $16^1$ статьясы нигезендә миңа

______________________________________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме, урнашкан урыны һәм адресы, эшчәнлек төрләре,
______________________________________________________________________
коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) нинди сыйфатта планлаштырыла)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) хезмәттән буш вакытта гамәлгә ашырылачак һәм били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә яисә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

__________ ____________________ 20____ елның «____»__________
(имза) (инициаллары, фамилиясе)

Гаризаларны теркәү
журналындагы теркәү номеры________________________________________________

Гаризаны теркәү датасы «___»___________20___ ел

________________ ____________________________________________________________
(имза) (гаризаны теркәгән затның вазыйфасы, инициаллары, фамилиясе)»;

6) түбәндәге эчтәлекле $2^2$ нче кушымта өстәргә:

«Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
$2^2$ нче кушымта

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итү турында гаризаларны теркәү журналы

| Т/с (гаризаны теркәү номеры) | Гаризаны теркәү датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза биргән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы | Гариза кабул иткән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы | Гаризаның күчермәсен алу турында билге («Күчермәне алдым», гариза биргән затның имзасы) | Яллаучы вәкиле кабул иткән карар турында билге | Гариза биргән затның яллаучы вәкиленең карары күчермәсен алуы турында («Күчермәне алдым», гариза биргән затның имзасы) йә яллаучы вәкиле карарын почта элемтәсе аша, тапшыру хакында хәбәр итеп, җибәрү хакында билге (карарны җибәргән затның адресы, имзасы) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 07 май
№ 20-ТРЗ